**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясьторак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“17” ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Шеканясь торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясь авылы территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (шеканясь торак пункты чокырын чистарту (үләнне чабу, агачларны, куакларны, үсентеләрне кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (шеканясь торак пунктының җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2024 елга гражданнар җыенында билгеләнгән буаны ремонтлау һәм төзекләндерү өчен гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 40 000 сум күләмендә акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә:
1)торак пункт территориясен төзекләндерү (шеканясь торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); балалар мәйданчыгын төзекләндерү (җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән ремонт, коймалар кору,

традицион Күмү урыннарын төзекләндерү өчен гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 5 000 сум күләмендә акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә :
 1) Ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны карап тоту һәм төзекләндерү (үләннәр чаптыру);
2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән торак пункт территориясен төзекләндерү һәм чистарту өчен гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 18 000 сум акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (шеканясь торак пунктының җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)- **мәсьәләсен кабул итәргә**.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Шеканясь авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясь авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе С.Н.Порфирьев